**СОВЕТ ГАБИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422606 с. Габишево,
пр. Молодежный, д.1
тел: 4-46-57

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ГАБИШЕВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422606 Габишев авылы,
Яшьләр урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-46-57

---

41номерлы 201916 декабре

# КАРАР

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишево авыл җирлеге составына керүче Габишево торак пунктындагы гражданнар җыены карары.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Габишево авыл җирлеге составына керүче Габишево торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Лаеш муниципаль районы Габишево авыл җирлеге Габишево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча урындагы мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

-"Габишево торак пункты территориясен төзекләндерү»,

- "Габишево торак пунктында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту";»,

- "Габишево торак пунктында суны зарарсызландыру җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру";»

3. Әлеге карарны Габишево авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишево авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче:_________________ Р.Т.Хусаинов

Башлык - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы-
Габишево авыл җирлеге Советы рәисе _________________ Р.Т.Хусаинов